РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 май, 2025 ел Кукмара ш. № 310

Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде**:

1. Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 статьяның 1 өлешендәге 14 пунктында «Татарстан Республикасы),» сүзләреннән соң «муниципаль белем бирү оешмаларында спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыру,» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карар, әгәр үз көченә керүнең башка сроклары законнарда каралмаган булса, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, рәсми рәвештә халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев